| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | | **КАРАР** |
|---|---|---|
| 13.12.2024 | г.Казань | № 468-10/тко-2024 |

«Идел буе экология компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.12.2020 ел, №549-9/тко-2020 карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларны 2025 ел өчен төгәлләштерү һәм Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.12.2020 ел, №549-9/тко-2020 карарына үзгәрешләр кертү турында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә инвестиция һәм җитештерү программаларын эшләү, раслау һәм төгәлләштерү тәртибен, шул исәптән эшкәртү, йогышсызландыру, күмү объектларының нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлы һәм факттагы күрсәткечләрен билгеләү, шулай ук инвестиция һәм җитештерү программаларын гамәлгә ашыруны тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2016 елның 16 маендагы 424 номерлы, «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә бәя кую турында» 2016 елның 30 маендагы 484 номерлы карарлары, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» 2016 елның 21 ноябрендәге 1638/16 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 13.12.2024 ел, № 32-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә, 2025 елга каты коммуналь калдыкларны күмүгә озак сроклы чик тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулаем кеременә төзәтмәләр кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Идел буе экология компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Идел буе экология компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән

җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә 2021 – 2025 елларга чик дәрәҗә тарифлар билгеләү турында» 17.12.2020 ел, №549-9/тко-2020 карары (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 16.11.2022 ел, №519-28/тко-2022, 12.01.2024 ел, №1-1/тко-2024 карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән билгеләнгән чик дәрәҗә тарифларны 2025 ел өчен төгәлләштереп, 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (кушымтада) бирергә.

2. Әлеге карарның 1 пункты белән төгәлләштерелгән тарифлар 2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Идел буе экология компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә 2021 – 2025 елларга чик дәрәҗә тарифлар билгеләү турында» 17.12.2020 ел, №549-9/тко-2020 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Идел буе экология компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә 2021 – 2025 елларга чик дәрәҗә тарифлар билгеләү һәм җитештерү программасын раслау турында»;

преамбулада «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә бәя кую турында» 2016 елның 30 маендагы 484 номерлы карары» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә инвестиция һәм җитештерү программаларын эшләү, раслау һәм төгәлләштерү тәртибен, шул исәптән эшкәртү, йогышсызландыру, күмү объектларының нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлы һәм факттагы күрсәткечләрен билгеләү, шулай ук инвестиция һәм җитештерү программаларын гамәлгә ашыруны тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2016 елның 16 маендагы 424 номерлы, «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә бәя кую турында» 2016 елның 30 маендагы 484 номерлы карарлары» сүзләре белән алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 3.1-3.2 пунктлар өстәргә:

«3.1. Әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендә «Идел буе экология компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җитештерү программасын расларга.

3.2. Әлеге карарның 3.1 пункты белән расланган җитештерү программасы 2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә.»;

3 нче кушымта белән тулыландырырга (кушымта итеп бирелә).

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
17.12.2020 № 549-9/тко-2020
карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
13.12.2024 № 468-10/тко-2024
карары редакциясендә)

Каты коммуналь калдыкларны күмү буенча «Идел буе экология компаниясе»
җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2021 – 2025 елларга календарь буенча бүленгән чик тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | 2021 ел | | 2022 ел | | 2023 ел | 2024 ел | | 2025 ел | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | | 12.01.2024 ел, №1-1/тко-2024 карар үз көченә кергән көннән | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән |
| | «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге | | | | | | | | | |
| 1 | «Идел буе экология компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | | | | | | | | | |
| | Каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик дәрәҗә тарифлар, сум/куб.метр | 160,56 | 172,35 | 172,35 | 186,31 | 217,66 * | - | - | - | - |
| | Каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик дәрәҗә тарифлар, сум/тонна | - | - | - | - | - | 1 679,21 | 1 970,02 | 1 970,02 | 2 707,54 |
| | Каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик дәрәҗә тарифлар, эшкәртүне исәпкә алмыйча, сум/тонна | - | - | - | - | - | 1 272,26 | 1 513,67 | 1 513,67 | 2 079,79 |

<*> 2023 елга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 16.11.2022 № 519-28/тко-2022 карары белән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карары нигезендә төзәтмәләр кертелгән тарифлар 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелде.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
17.12.2020 № 549-9/тко-2020
карарына 3 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
13.12.2024 № 468-10/тко-2024
карары редакциясендә)

<table>
<tr><td colspan="6">Оешманың җитештерү программасы</td></tr>
<tr><td colspan="6">1 нче бүлек. Җитештерү программасы паспорты</td></tr>
<tr><td colspan="2">Җайга салынулы оешма</td><td colspan="4">Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең «Идел буе экология компаниясе» ҖЧҖ</td></tr>
<tr><td colspan="2">Урнашкан урыны</td><td colspan="4">Татарстан Республикасы, Чаллы шәһәре, Автосборочный тыкрыгы, 29/63</td></tr>
<tr><td colspan="2">Җайга салуның вәкаләтле органы</td><td colspan="4">Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты</td></tr>
<tr><td colspan="2">Урнашкан урыны</td><td colspan="4">420015, Татарстан Республикасы, Казан ш., Карл Маркс ур., 66 й.</td></tr>
<tr><td colspan="2">Җитештерү программасын гамәлгә ашыру чоры</td><td>башлана</td><td>01.01.2025</td><td>тәмамлана</td><td>31.12.2025</td></tr>
<tr><td colspan="6">2 нче бүлек. Җитештерү программасы чараларын гамәлгә ашыру исемлеге</td></tr>
<tr><td rowspan="2">№</td><td rowspan="2" colspan="2">Аталышы</td><td rowspan="2">Үлчәү берәмлеге</td><td colspan="2">Гамәлгә ашыруга финанс ихтыяҗлары</td></tr>
<tr><td colspan="2">2025 ел</td></tr>
<tr><td>1</td><td colspan="2">Объектларны агымдагы ремонтлау</td><td>мең сум</td><td colspan="2">491 711,73</td></tr>
<tr><td>2</td><td colspan="2">Агымдагы ремонт</td><td>мең сум</td><td colspan="2">31 663,77</td></tr>
<tr><td>3</td><td colspan="2">Капиталь ремонт</td><td>мең сум</td><td colspan="2">0,00</td></tr>
<tr><td colspan="6">3 нче бүлек. Күмелә торган каты коммуналь калдыкларның планлаштырылган массасы</td></tr>
<tr><td rowspan="2">№</td><td rowspan="2" colspan="2">Җитештерү эшчәнлеге күрсәткечләре</td><td rowspan="2">Үлчәү берәмлеге</td><td colspan="2">Күрсәткеч зурлыгы</td></tr>
<tr><td colspan="2">2025 ел</td></tr>
<tr><td>1</td><td colspan="2">Каты коммуналь калдыкларның массасы</td><td>мең тонна</td><td colspan="2">223,78</td></tr>
<tr><td colspan="6">4 нче бүлек. Финанс ихтыяҗлары күләме</td></tr>
<tr><td rowspan="2">№</td><td rowspan="2" colspan="2">Күрсәткеч</td><td rowspan="2">Үлчәү берәмлеге</td><td colspan="2">Күрсәткеч зурлыгы</td></tr>
<tr><td colspan="2">2025 ел</td></tr>
<tr><td>1</td><td colspan="2">Җитештерү чыгымнары</td><td>мең сум</td><td colspan="2">262 664,47</td></tr>
<tr><td>1.1</td><td colspan="2">Материаллар һәм азкыйммәтле төп чаралар</td><td>мең сум</td><td colspan="2">59 569,19</td></tr>
<tr><td>1.2</td><td colspan="2">Электр энергиясенә чыгымнар</td><td>мең сум</td><td colspan="2">7 672,92</td></tr>
<tr><td>1.3</td><td colspan="2">Каты коммуналь калдыкларны эшкәртү, зарарсызландыру, күмү өчен файдаланыла торган</td><td>мең сум</td><td colspan="2">61 405,76</td></tr>
</table>

| | | | |
|---|---|---|---|
| | объектлардан эксплуатацияләүгә бәйле чит оешмалар яисә шәхси эшкуарлар тарафыннан башкарыла торган эшләр һәм (яисә) хезмәт күрсәтүләр өчен түләү чыгымнары | | |
| 1.4 | Төп җитештерү персоналының хезмәте өчен түләү һәм социаль ихтыяҗларга чигерү чыгымнары, шул исәптән салымнар һәм җыемнар | мең сум | 35 573,26 |
| 1.5 | гомумхуҗалык чыгымнары | мең сум | 34 951,09 |
| 1.6 | Башка төр җитештерү чыгымнары | мең сум | 63 492,25 |
| 2 | Ремонт чыгымнары | мең сум | 31 663,77 |
| 3 | Административ чыгымнар | мең сум | 23 609,13 |
| 4 | Саты чыгымнары (шикле бурычлар) | мең сум | 0,00 |
| 5 | Амортизация | мең сум | 11 688,19 |
| 6 | Аренда түләвенә, лизинг түләүләренә, концессия түләвенә чыгымнар | мең сум | 28 845,45 |
| 7 | Салымнар һәм җыемнар түләүгә бәйле чыгымнар | мең сум | 839,93 |
| 8 | Каты коммуналь калдыкларны урнаштырганда әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаган өчен түләү чыгымнары | мең сум | 20 770,25 |
| 9 | Эшчәнлекнең җайга салына торган төрләрен гамәлгә ашыручы башка оешмалардан сатып алына торган товарлар (хезмәт күрсәтүләр, эшләр) өчен түләү чыгымнары | мең сум | 0,00 |
| 10 | Башка төр контрольлектә булмаган чыгымнар | мең сум | 0,00 |
| 11 | Алынмаган керемнәр / Төшеп кала торган чыгымнар | мең сум | 143 907,25 |
| 12 | Узган чорда тарифлар билгеләгәндә тарифларны җайга салу органы тарафыннан исәпкә алынмаган икътисадый нигезләнгән чыгымнар | мең сум | 0,00 |
| 13 | Җайга салуның узган чорларының икътисадый яктан нигезләнмәгән керемнәре | мең сум | 18 578,47 |
| 14 | Исәпләнгән эшкуарлык табышы | мең сум | 17 965,55 |
| 15 | Кирәкле тулай табыш | мең сум | 523 375,50 |
| **5 нче бүлек. Җитештерү программасы чараларын гамәлгә ашыру графигы** | | | |
| **№** | **Чараның аталышы** | **план чоры** | |
| 1 | Агымдагы ремонт | 2025 ел | |
| **6 нчы бүлек. Объектларның нәтиҗәлелек күрсәткечләренең план һәм факт күрсәткечләре** | | | |
| **№** | **Күрсәткеч** | **Үлчәү берәмлеге** | **Күрсәткеч зурлыгы** |
| | | | **2025 ел** |
| 1 | Эшчәнлек башкаруга экологик тикшерү нәтиҗәләре буенча сайлап алынган җир асты сулары, туфрак һәм һава пробаларының гомуми өлешендә мондый пробаларның билгеләнгән таләпләргә туры килми торган өлеше | % | 0,00 |
| 2 | Каты коммуналь калдыкларны күмү объекты мәйданы берәмлеге исәбеннән каты коммуналь калдыкларның яныр китү очраклары саны | % | 0,00 |
| **7 нче бүлек. Җайга салуның узган чорында җитештерү программасының үтәлеше турында хисап** | | | |
| Җайга салуның узган чорында җитештерү программасының үтәлеше турындагы хисап оешманың 2023 елгы финанс-хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәләре турындагы хисабы составында бирелгән. | | | |